№6 (06) февраль, 2018 ел 

# ХЫЯЛ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫ
“ЧАЛМАНАРАТ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”НЕҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ







**3 – Татарстанның халык язучысы Фатих Хөснинең туууына 110 ел (1908–1996).**

**15 – Шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның тууына 80 ел (1938–2009).**

**22 – Язучы, сәясәт эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел (1878–1954).**



**9 – Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллинның тууына 80 ел (1938–2011).**



**Ф.Яруллинның тууына 80 ел тулуга багышланган кичә уздырылды.**

## 21 нче февраль – Халыкара туган тел көне

*“Берәү башка телне өйрәнмәкче булса, башта үз теленең грамматикасын белсен”*, - дигән Каюм Насыйри.

Туган телем син – йөрәк
жылысы,
Туган телем син – күңел
тойгысы,
Туган телем син – тарих
баскычы,
Туган телем син – белем
ачкычы.



Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ә.Р.Исрафилова Халыкара туган тел көне уңаеннан башлангыч класс укучылары белән кичә-викторина уздырды.

Укучылар төрле эчтәлек-тәге биремнәр үтәделәр, кроссвордлар чиштеләр, үз фикерләре белдереп, мәкальләр һәм табышмак-ларның эчтәлекләрен ачтылар. Камалетдинов Самат (IIIкл.) – I; Зарипов Раил (IVкл.) - II; Кашапова Наилә (IIIкл.) - II; Вәлиева Энже (IVкл.) - III; Булатов Нәфкать (IIIкл.) III урын алдылар һәм “Мактау кәгазе” белән бүләкләнделәр.


**Адилә Манихова**
**VI класс укучысы**

## Әфганстан.

Күпләрне тетрәндергән сүз бу. Леонид Брежнев Әфганстанга совет гаскәрләре кертелү турындагы хәбәрне Үзәк телевидение буенча 1979 нчы елның 25 нче декабрендә игълан итте.

1988 нче елның 15 нче маенда гына чит илдәге гражданнар сугышыннан совет гаскәрләре чыгарыла башлады һәм, ниһаять, 1989 нчы елның 15 нче февралендә соңгы совет солдаты Әфганстан чиген атлап чыкты. 9 ел 51 көн буена барган сугыш булды бу җирдә.

Бу сугыш безнең халык өчен 15 меңгә якын кургаш табут, 50 мең ярады, 312 хәбәрсез югалган солдат рәвешендә әйләнеп кайтты. Исән кайтканнар мәңге төзәлмәс күңел җәрәхәте алды. ТР Әфганстан сугышында менә дигән 257 егетен югалтты.

| | | | |
|---|---|---|---|
|  | ***Фазлыев Дәһлүл Вәли улы.*** ***Тыңламас авылыннан.*** *1960 нчы елның 18 нче июлендә туа, 1980 нче елның 2 нче августында үтерелә.* ***Яшәгән гомере – 20 ел, 14 көн.*** |  | ***Зәйнетдинов Ринат Әзһәр улы.*** ***Иске Богады авылыннан.*** *1961 нче елның 22 нче мартында туа, 1981 нче елның 6 нчы июлендә үтерелә.* ***Яшәгән гомере – 20 ел, 3 ай, 14 көн.*** |
|  | ***Сафин Мөхәррәм Нәсим улы.*** ***Уразай авылыннан.*** *1962 нче елның 26 нчы июлендә туа, 1981 нче елның 21 нче маенда үтерелә.* ***Яшәгән гомере – 18 ел, 10 ай, 25 көн.*** |  | ***Мирсәетов Мөдәррис Миргаяз улы.*** ***Меңнәр авылыннан.*** *1963 нче елның 1 нче сентябрендә туа, 1982 нче елның 26 нчы сентябрендә үтерелә.* ***Яшәгән гомере – 19 ел, 26 көн.*** |
|  | ***Фәррахов Рамил Госсам улы.*** ***Иске Байсар авылыннан.*** *1961 нче елның 3 нче июлендә туа, 1981 нче елның 22 нче маенда үтерелә.* ***Яшәгән гомере – 19 ел, 10 ай, 19 көн.*** |  | ***Фәрдиев Рәшит Салихҗан улы.*** ***Зөбәер авылыннан.*** *1965 нче елның 13 нче маенда туа, 1985 нче елның 26 нчы октябрендә үтерелә.* ***Яшәгән гомере – 20 ел, 5 ай, 13 көн.*** |

***Чалманарат авылыннан Илдус абый Нуртдинов һәм Лемар абый Ханнанов Әфганстан сугышында катнашканнар. Бүген алар туган авылларында яшиләр.***

# УКУДА



Район күләмендә уздырылган инглиз телендә сочинение язу бәйгесе



Диана
Роберт кызы Акбулатова
II урын

Шәфкәт
Шамил улы Булатов
III урын

География укытучыларының районкүләм "Мастер-класс" бәйгесе бәйгесе



Алмазия
Тәминдар кызы
Рәхимова
III урын

# ИЖАТТА

Күренекле мәгърифәтче, галим Ибраһим Хәлфин исемендәге XIII республикакүләм фәнни-эзләну укучылар конференциясе



Рус теле һәм әдәбияты укытучысы – Раушания Сәйфулла кызы Галимҗанова – II; VIII класс укучылары: Миләүшә Алмаз кызы Фазлыева – I, Сәйдәш Сәлим улы Шакиров – II урын.

Республикакүләм “Аяз Гыйләҗев укулары” фәнни-эзләну конференциясе



С.С.Шакиров – призёр;
Д.Р.Акбулатова - лауреат

## *Сезнең белән горурланабыз, Гөлнара апа!*

**Район үзәгендә уздырылган җитәкчеләр спартакиадасында 45яшьтән өлкәнрәк булган хатын-кыз җитәкчеләр арасында “Җиңүче” исеменә мәктәбебез директоры - Гөлнара Әхмәтова Рафаэль кызы лаек булды.**
**Чаңгыда - II; йөзүдә – III; бадминтон ярышында – IV урын.**





## *Ял сәгатьләрендә*

### Яшел шар ничәү?

*24 шарны бер бауга бәйләгәннәр. Аның нәкъ яртысы һәм тагын икесе – кызыл, калган яртысы һәм тагын берсе – сары, тагын да калганнарының яртысы һәм икесе – зәңгәр, калганнары яшел төстә. Яшел шар ничәү?*

### Икебезгә бер хәреф.

*Сулдагы ике сүзгә дә бер үк хәреф (алга, уртага яки артка) кушып, яңа сүз төзегез. Мәсәлән, кыл, кеш +а = акыл, каеш. Яңа сүзне уң якка, уртак хәрефне баганага яза барыгыз. Нинди сүз килеп чыкты?*

| | | |
|---|---|---|
| Исем, өй | | |
| Грант, пи | | |
| Банк, бот | | |
| Бет, ләм | | |

***Котлыйбыз!***
**23 нче февраль –**
**Ватанны саклаучылар көне.**
**Әтиләребезне, укытучы абыйларны, малайларны, егетләрне бәйрәм белән тәбрик итәбез!**
**Чын ир-егетләр булыгыз!**

«Хыял» Чалманарат төп гомуми белем бирү укучыларының фәнни-популяр, әдәби-нәфис айлык басмасы
Шеф-мөхәррир: Диана Акбулатова Җаваплы сәркатип: Миләүшә Фазлыева Фотохәбәрче: Сәйдәш Шакиров
Безнең адрес: 423752, Чалманарат авылы, Мәктәп ур., 7 нче йорт. E-mail: Schal.Akt@edu.tatar.ru, chalm.akt@yandex.ru
Тираж: 15 данә Кул куелды: 08.00; 28.02.2018
Мәктәп компьютерында басылды. Бәясе ирекле. Мәкаләдәге фикерләр өчен мөхәррият җавап тотмый.